Казан шәһәре Совет районы “Күп профильле 181 нче мәктәп”
№3 ноябрь 2022 ел

# «Күкнең җиденче катында»

## Котлыйбыз!



Салкын кышларга кереп барганда, без иң җылы һәм якты бәйрәмнәрнең берсен - Әниләр көнен билгеләп үтәбез. Безгә тормыш бүләк иткән, бөтен йөрәк җылысын биргән, безнең өчен тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр кичергән газизләребезгә нинди генә теләкләр теләсәк тә аз булыр сыман. Тормышыбыз бизәге булган әниләребез матур да, батыр да, мәрхәмәтле дә
салкын кышларга кереп барганда, без иң җылы һәм якты бәйрәмнәрнең берсен - Әниләр көнен билгеләп үтәбез. Безгә тормыш бүләк иткән, бөтен йөрәк җылысын биргән, безнең өчен тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр кичергән газизләребезгә нинди генә теләкләр теләсәк тә аз булыр сыман.Тормышыбыз бизәге булган әниләребез матур да, батыр да, мәрхәмәтле дә, изге күңелле дә.

Без төпле киңәшләр сорап сезнең янга киләбез, сезнең һәрчак безне аңлавыгызны, ярдәмегездән ташламавыгызны беләбез. Сез гаилә учагын, тынычлыкны саклаучылар. Балалар гына түгел, ә бөтен җәмгыять аналар канаты астында. Мәхәббәтегез, сабырлыгыгыз, назыгыз һәм ниләр генә кылсак та гафу итә белүегез өчен сезнең алда баш иябез. Сезнең иңнәргә бик зур йөк - гаилә мәшәкатьләре дә, һөнәри эшчәнлек тә, балалар тәрбияләү дә төшә. Барысы өчен дә бик зур рәхмәт! Кадерледән кадерлеләребез!Сезгә озын гомер, имин көннәр, балаларыгызның куанычларын гына күреп яшәвегезне телибез.Күңелегез тыныч, килер көннәрегез матур һәм һәрчак бәхетле булыгыз!





## Иҗат җимешләре

## Әниемнең йомшак куллары

Дөньяда иң йомшак, назлы, җылы куллар кемдә дисезме? Ул - әниләрдә!

Иртән йомшак, җылы куллар сине сыпырып

уята, тәмле ризыклары белән сыйлап, сине шатландыра, авырган чакта да шушы шифалы куллар сиңа сихәт бирә.

Кадерле әниләр! Сезнең йөрәк җылыгыз белән кушылган кул җылылыкларыгыз, сезнең мәхәббәтегезне тоеп, озак яшәргә язсын!

Бәйрәмегез белән Сезне!

Ибраһимова Сабина

10А сыйныфы

## Яраткан һөнәрем- тәрбияче

Минем яраткан һөнәрем- тәрбияче. Кем соң ул тәрбияче? Күп кеше бу сорауга “балалар караучы” дияр иде. Ләкин бу һөнәр үз эченә күп төрле һөнәрләрне туплый. Мисал өчен: укытучы, өйрәтүче, артист, яңадан яңа төрле идеялар уйлап табучы, тел остасы. Моның өстенә ата-аналар белән көнгә ике тапкыр күрешеп аралашучы.

Тәрбияче - балаларны яратучы, аларның телендә сөйләшеп эчке уйлауларын кичерешләрен аңлаучы, димәк, психолог та.

Тәрбияче балалар белән гел актив тормыш алып бара. Көн саен балалар күңелендә орлык салып үстерүче. Үзе үстергән орлыкларның “җимешләрен” күргәч, тәрбияче бер баскыч “өскә атлый”.

Балаларны ярату, аңлау бөтен кешегә дә бирелми, үзеңне мәҗбүр итеп балаларны яраттырып булмый.

Асланова Нәргиз

9Б сыйныф укучысы



## “Кәгазь эшкәртүнең “уңай” һәм “тискәре” яклары

Кәгазь эшкәртүнең уңай һәм тискәре яклары булырга мөмкин. Әлбәттә, уңай яклары күбрәк. Беренчедән, кешеләр кирәк булмаган кәгазьдән котыла. Кәгазьне яңадан эшкәртеп, без бер генә булса да агачны коткарабыз. Кәгазь тапшырган акчаны кирәк әйберләргә куллана, яки хәйрия итеп каядыр тапшыра алабыз.

Тискәре якларына килгәндә, алар юк диярлек.


Безнең мәктәптә елына ике тапкыр гына кәгазь җыялар, ешрак булса, әйбәт булыр иде, дип уйлыйм мин.

Минемчә, кәгазь җыю, безне тәрбияли.

Әйдәгез, урманнарны кисмик, кирәкмәс китапларны, кәгазьләрне тапшырыйк!

Вахитов Азат,

9Б сыйныфы



## Бездә кунакта бизнес психолог Яна Вознюк



Ноябрь ахырында мәктәбебезгә кунакка психолог Яна Вознюк килеп, укучылар белән “җанлы” әңгәмә уздырды.

*-Уңышларга ирешкән кеше кем ул?*
*-Уңышларга ничек ирешеп була?*
*-Ни өчен берәүләргә уңыш “елмая”, икенчеләргә “юк”?!*

Яна Вознюк әлеге һәм башка сорауларга тулы җавап биреп узды.

1.Тырышып уку.
2.Белемеңне тирәнәйтү
3. Максат кую, аңа ирешү.
4.Үз-үзеңә ышану.
5.Үзбәяңне күтәрү.



Һәр эшне эшли башлаганда, максатны куя белергә һәм аны үтәүне бурыч итеп куярга кирәк. Эшең беренче тапкыр барып чыкмаса, хафаланма, тагын эшләп кара. Үз-үзеңә ышан!

Әлбәттә, уңышка ирешү өчен күп укырга, күзаллавыңны киңәйтергә, төрле треннингларда катнашырга кирәк. Эшләрең барып чыкмаган очракта һәр эшнең дә уңай ягын табарга тырыш. Борчылма! Тынычлан һәм эшеңне дәвам ит!



Өлкән сыйныф укучылары акча тоту, аны кирәкмәскә сарыф итмәүне уйларга тиеш. Шул очракта Сез , күп акча туплап, үз эшегезне ачып җибәрә, бизнес белән шөгыльләнә аласыз.

Кадерле укучылар! Сез киләчәгегезне бүгеннән үк уйлап, планлаштыра башларга тиеш, дип сүзен тәмамлады Яна Вознюк.







**4 ноябрь** - Халыклар бердәмлеге көне.

Бу бәйрәмнең тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Ул тынычлык, иминлек, бәйсезлек өчен бердәмлек символын чагылдыра. Әйе, уртак көч булып туплансак, авыр чакта бер-беребезгә ярдәм кулы сузсак, җәмгыятебездәге вакыйгаларга битарафлык күрсәтмәсәк, төрле дин һәм милләт халкына, аларның гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карасак, без - көчле халык....

Үткәннәр бит үткән көннәр инде,
Бүгенге көн кыйммәт гел, дибез,
Бүгенге көн дә бит, бер уйласаң,
Үткән көнгә кайтыр көнебез.
Нәрсә ул көн… Тарих битләрендә,
Еллар… Эраларга тиң түгел.
Гасырлардан гасырларга шулай
Кеше гомере дә бер мизгел.
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Ни иккәнен, ни чиккәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.
Исеңдә тот, аларның син
Сугышларда кан түккәнен,
Туган җирнең иреге өчен
Зинданнарда интеккәнен…



**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
**Тираж** – 50 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы
**Редколлегия әгъзалары:**
Ибраһимова Сабина, Башмаков Богдан, Вахитов Тимур, Соколова София

***

Балаларның көлешкәнен
Ишетсен Җир, тыңласын Җир!
Балаларның көлүеннән
Берчакта да тынмасын Җир!

Ә балалар көлә икән
Илебездә, Җиребездә,
Димәк, Җир дә исән әле,
Имин, димәк, Илебез дә!